ГЛАВА
МАЙНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МАЙНА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

**КАРАР** с.Верх.Тат.Майна **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**30.10.2019** **№ 18**

**Алексеевск муниципаль районының**
**“Майна җирлеге территориясендәге**
**Баганалы урман хуҗалыгы бистәсендә**
**үзара салым кертү һәм гражданнарның**
**үзара салым акчаларыннан**
**файдалану мәсьәләсе буенча**
**гражданнар җыенын билгеләү турында “**

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ” Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында “Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы», Алексеевск муниципаль районы Майна авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә,

**Карар бирәм:**

1. Алексеевск муниципаль районының Майна җирлеге территориясендәге Баганалы урман хуҗалыгы бистәсендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча 2019 елның 13 нче ноябре көнне 14 сәг 00 минутта гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:
Алексеевск муниципаль районы Майна җирлеге территориясендәге Баганалы урман хуҗалыгы бистәсендә 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә, үзара салымны, барлык шул җирлек территориясендә теркәлгән, балигъ булган затлардан, хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге уку бүлеге студентларыннан тыш, җыюга һәм акчаларны җирле түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотуга сез ризамы?

- торак пунктта урамнарны яктырту;
- чүп контейнерлары сатып алу һәм урнаштыру;

" ӘЙЕ " КАРШЫ"

3. Халык җыенын оештыручы итеп Алексеевск муниципаль районы Майна авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

4. Җыенның үткәрү урыны дип урман хуҗалыгы конторасын билгеләргә. Адресы: Татарстан Республикасы, Алексеевск районы, Баганалы урман хуҗалыгы бистәсе, Лесная урамы, 5а санлы йорт.

5. Әлеге карарны Майна авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы, Алексеевск муниципаль районы, Баганалы урман хуҗалыгы бистәсендә, Лесная урамы, 5а санлы йорт адресындагы мәгълүмат стендында урнаштырырга.

6. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районы**
**Майна авыл җирлеге башлыгы**
**Совет Рәисе** **Р.Н.Гафиятуллин**